

Укытучы – ин авыр, ин катлаулы, ин кирәкле, шул ук вакытта ин гvзәл, ин гуманлы һонәрләрнен берсе. Бу һонәрне сайлаган кеше гажәеп дәрәжәдә тәрбияле, гыйлемле булырга тиеш. Нәкъ шундый укытучылар Кадошкино районы Большие Поляны авылындагы Капкаевлар династия-се, дәвамчылары белән бергә. Аларнын нәселендәге педагогик стаж барлыгы 800 елны тәшкил итә. Килешәсездер, сирәк һәм кvнелле факт. Сvзем алар турында.      Большая Поляна авылында оешкан советлар мәктәбенен беренче укытучыларыннан Умәр Хикмәтулла улы Капкаев (1870-1937) була. Авылы халкы аны белем алырга дип Уфа шәһәрендәге мәдрәсәгә юллый. Белем алып кайткач, авылдагы алты мәчетнен берсендә мулла була һәм мәдрәсәсе дә эшләгән. Революциягә кадәр һәм аннан сон мәктәптә география фәнен алып барган; халык ышанычын аклаган. 1937нче елда Умәр Хикмәтулла улы Капкаевны репрессиялиләр. Бераздан аны аклыйлар - реабилитациялиләр.

Капкаевлар гаиләсендә биш бала - Мо-хәммәтша, Вәли, Фәридә, Монирә, Рашид- укытучы профессиясен сайлыйлар. Кызлары Эмеголсем, укытучы Х.Я.Маракаевка кияvгә чыга; ул озак еллар мәктәп директоры булып эшли.

Умәр Хикмәтуллович Капкаевнын улы Мохәммәтша Умәрович (1903-1959) Пенза шәһәрендәге педагогик техникумны тә-мамлап (образование неоконченное высшее), туган Большие Поляны мәктәбендә биология фәне буенча авылдашлары балаларына белем бирә; 1943 елда мәктәп директоры итеп билгелиләр һәм 1955 елга кадәр шул вазыйфада була. Авыл халкы анын акылы, белеме һәм абруе очен хормәт итә торган булалар. Ул 1941 елнын августында Боек Ватан сугышына китә. Сугыштан ул «За боевые заслуги» медале һәм кvкрәгендәге ярасы белән кайта. Янадан директорлык эшен дәвам иттерә.  Тырыш хезмәте «Знак Почета» ордены белән билгеләнгән.



Анын дvрт баласыннан очесе - укытучы. Берсе - Сәгидә Мохәммәтжан кызы Капкаева

(1926-2003) Мордовия укытучылары институтынын естественно-географичес-кий факультетын тәмамлый. Туган авылы мәктәбендә укучыларга 33 ел география предметы буенча белем бирә; педагогик хезмәт ветераны. Анын улы -  Шамиль Закир улы Капкаев (1954-1978) Н.П.Огарев исемендәге МГУнын химия факультетын тәмамлый. Шул ук районнын Паево авылы урта мәктәбендә бер ел химия укыта. Ә Мохәммәтша абыйнын кече кызы Сания гомере буе Кадошкино районы туган авылы Большие Поляны урта мәктәбендә математика укытты. Ул физика белән математика буенча белемне башта А.И.Полежаев исемендәге Мордовия укытучылар институтында ала, аннары - В.Г.Белинский исемендәге Пенза педагогия институтында математика белгечлеге дипломын яклый. Сания Мохәммәтша кызы Капкаева 40 ел балаларга предметы буенча белем һәм тәр-бия бирә. Үзенен педагогик эшчәнлеге һәм зур эш стажы очен “МАССРнын атказанган халык мәгарифе хезмәткәре” исеменә лаек. Хәзер ин олкән педагогка 93 яшь. Әмма Сания Мохәммәтша кызы элеккечә vк математика буенча программага кертелгән яналыклар белән кызыксына. Үз оныклары белән ЕГЭга әзерлек белән шогыльләнә... әлбәттә, ветеранны Россиянен бvгенгесе һәм киләчәге, анын оныклары Һәм оныкчык-лары кызыксындыра.
Сания Мохәммәтша кызынын барлык укучылары да анын Совет фильмнарында кvрсәтелгәнчә, классик укытучы, диләр. Мин дә шулай дим, чонки анын предметын яратмыйча булдыра алмый идек. Сания Мохәммәтша кызы предметын яхшы белvче, дәрес бирv методикасын нык vзләштергән  cvз остасы да булды. Зәвыклы киенгәне дә исемдә.
Анын ике кызы да укытучы. Олысы - Рима Ариф кызы Уторова (Капкаева, 1954) Казан педагогия институтынын математика факультетын тәмамлый һәм Паево мәктәбен-дә бер ел эшләп олгерә. Киявгә чыгып, Челябинск шәһәренә кvчеп яшиләр. Анын 2 баласы да укытучы: Лилия Равиль кызы Уторова (1977) М.Е.Евсевьев исемендәге педагогия институты тәмамлап, Челябинск шәһәрендәге №100 мәктәптә директор урынбасары булып хезмәт итә. Улы - Олег Равильевич (1981), Челябинск педагогия университетынын тарих һәм хокук факультетында юриспруденция белгечлеге буенча белем ала. Педагогия фәннәре кандидаты.
С.М.Капкаеванын кече кызы - Мангутова (Капкаева) Наилә Ариф кызы (1956), Н.П.Огарев исемендәге МГУнын тарих факультетын тәмамлый. 35 ел туган авылы мәктәбендә тарих һәм жәмгыять предметларын укыта. Ул - хезмәт ветераны, Почетный работник общего образования РФ. Анын тормыш иптәше Наиль Шәvкәт улы Мангутов (1956) М.Е.Евсевьев исемендәге педагогия институтында физкультура укытучылары әзерләгән бvлекне тәмамлап, оч дистә еллар туган авылы мәктәбендә эшли. Ул – хезмәт ветераны, Отличник физической культуры РФ иде.



[illegible]